| ГЛАВА<br>Девятернинского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Девәтернә авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.10.2024 Девәтернә авылы № 5

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Девәтернә авыл җирлеге Уставының 14 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Девәтернә авыл җирлеге Башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 18 октябрендә 08 сәг 00 мин билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2025 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Девәтернә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Нарат торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәттәгеләр, мобилизацияләнеп, үз теләкләре буенча китүчеләр) һәм аларның гаилә членнарын (бергә яшәүче әти-әниләре, тормыш иптәшләре, балигъ булган балалары) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- торак пункт территориясендә уңайлыклар булдыру (хуҗалыклар, электр линияләре өчен куркыныч тудыручы һәм корыган агачларны кисү һәм чыгару, урамнарда чүп чабу, юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр сатып алу; дизель ягулыгы һәм май